РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМАНАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ» АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«УРМАНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ул. Татарстан д.15«а», с.Урманаево,
Азнакаевский район, 423311

Татарстан урамы, йорт 15 "а", Урманай авылы
Азнакай районы, 423311

Тел./факс(8-85592)4-30-49/4-31-56; E-mail Azn.Urman@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 22 » ноябрь 2021ел № 06

2022 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Уставынын 15.1 статьясы нигезендә, карар итәм:

1.Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май бистәсе торак пунктында теркәлгән Верхняя урамы буенча 01 йорттан 33 йортка кадәр, Нижняя урамы буенча 01 йорттан 16 йортка кадәр теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2021 елның 04 декабрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май бистәсе торак пунктында теркәлгән Средняя урамы буенча 01 йорттан 12 йортка кадәр, Нижняя урамы буенча 17 йорттан 35 йортка кадәр теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2021 елның 04 декабрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

3. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май бистәсе торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитеты;

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2022 елда Урманай авыл җирлеге Беренче Май бистәсе торак пункты территориясендә Беренче Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү (бүләк һәм сувенир продукция сатып алу, «Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне " бәйрәм чараларын үткәрү хезмәтләре күрсәтү»);

- Беренче Май бистәсе торак пунктында Средняя һәм Верхняя урамнарында асфальт-бетон өслекле юллардагы чокырларны ямау (килешү буенча сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү);

**«РИЗА»** **«КАРШЫ».**

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

6. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

.

Башлык: ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ УРМАНАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЗНАКАЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН А.И.Закиров